Максат: алдауның, ялганның кеше абруен югалта торган кире сыйфатлар икәнлегенә төшендерү.

Дәрес барышы.

I. Өйгә бирелгән эшне тикшерү.

1. Үз-үзеңә бәя кую.

II.Уку мәсьәләсен кую.Рәмзия апа, эштән кайтып, өс - башын алыштырырга да өлгермәде, тышкы ишектә кыңгырау шалтырады.

- Улым, бар әле, син ач,- диде ана залдагы диванда телевизор карап утырган Азатка.

Малай теләр-теләмәс кенә урыннан кузгалды һәм аяк очларына басып кына ишек янына килде дә андагы тишеккә карады. Сыйныф җитәкчесенең таныш йөзен күргәч, бер мәлгә катып калды. Аның башыннан яшен тизлегендә “ Ул минем 2леләр турында сөйләргә килгән, мөгаен. Бәлки ишекне ачмаска? Басып торыр-торыр да, түземлеге беткәч, кире китәр”, - дигән уйлар йөгереп үтте. Ләкин Азат төпле генә бер карарга килергә дә өлгерә алмый калды, колак төбендә кабат әнисенең ягымлы тавышы яңгырады:

- Нигә, улым, кешене көттерәсең?

Малай keләне уң якка тартты.

- Әллә вакытсызрак килеп, сезгә комачаулык ясадым инде?- диде сыйныф җитәкчесе, үзен ни өчендер уңайсыз тоеп. – Алай дисәң, сезгә киләчәгемне ике көн элек үк Азатка әйтеп җибәргән идем.

Рәмзия апа гаҗәпләнеп улына карады:

- Беренче тапкыр ишетәм.

Азат, ни әйтергә белмичә, баганадай басып тора бирде. Аңа ярдәмгә сыйныф җитәкчесе килде.

- Азатның онытканбулуы да ихтимал. Аннары сез авырып та торгач, көяләндермим дә дигәндер, - диде ул Рәмзия апага карап. – Ничек соң, терелдегезме инде?

- Гафу итегез, сез мине башка кеше белән бутамыйсызмы? – дип сорады ана, бер сыйныф җитәкчесенә, бер Азатка карап.

- Ходайга шөкер, өч ел инде чирнең ни икәнен дә белгәнем юк.

- Юк, һич кенә дә ялгышмыйм, сез Азат Мирхазовның әнисе,- диде сыйныф җитәкчесе.- Азат сезнең хакта: “Әнием ике атна була инде, авырып тора,”- дигәч, түзмәдем, хәлегезне белергә ашыктым. Аннары Азатның 3-4 фәннән билгеләре дә йомшарды....

Хәзер инде Рәмзия апа эшнең нәрсәдә икәнен исләп алды һәм сүзне икенчегә борып:

- Әйдәгез, залга үтеп сөйләшик, чәй дә куйган идем, - дип, көтелмәгән кунакка чишенергә тәкъдим ясады....

Төркемнәргә тикшерү өчен сораулар:

- Азатларга килү өчен сыйныф җитәкчесенә нәрсә сәбәп булган?

- Рәмзия апаның авыруы.

- Ул чынлап та авырганмы соң?

- Юк, әлбәттә Азат укытучыны алдаган.

- Ни өчен?

- Чөнки ул 3-4 фәннән начар билгеләре алган. Шуларны әнисенә белдерергә теләмәгән, күрәсең.

- Димәк, бүген дәрестә нәрсә турында сүз алып барачакбыз?

- Алдауның, ялганның кеше абруен югалта торган кире сыйфатлар икәнлеге турында.

Үз-үзеңә бәя кую.

III. Уку мәсьәләсен чишү.

Төркемнәрдә тикшерегез:

1нче бирем.

-Нәрсә ул алдау?

-1. Хәйләләү, хәйләләп нәрсәсен дә булса алу; кешене авыр хәлдә калдыру; кешегә начарлык эшләү.- Нәрсәгә, нәрсәгә, мин синең алдавыңа исәп тотмаган идем.

2. Ялганлау, ялган сөйләү.- Байлык алдата инде ул.

3. Ялган сөйләп кешене ялгыштыру, ялгыш фикергә китерү, ялганга ышандыру.- Мин бер тапкыр сиңа ышанган идем инде, хәзер алдый алмассың.

4.Кызыктыру. Мин бала-чага түгел, кәнфит күрсәтеп кенә алдый алмассың.

5. Саташтыру, ялгыштыру, башкача булып күренү яки ишетелү. – Мин сине хур кызларына охшатып ялгыштым, тирән ялгыштым.

6. Вәгъдә бозу, хыянәт итү.- Син мине алдарсың дип башыма да китермәдем.

7. Ялгышу.- Хәтергә хәзер ышаныч бәләкәй, кайчак алдалый.

- Нәрсә ул ялган?

- Хакыйкатьне бозып күрсәтә торган, дөрес булмаган, чын булмаган.- ялган хәбәр, ялган караш, ялган акча, ялган хис һ. б.

- Алдау, ялган һәм хәйлә сүзләре арасында уртаклык бармы?

Бар, әлбәттә. Хәйлә төшенчәсе урыны белән алдауны да, ялганны да үз эченә ала.

Хәйлә - 1.Нинди дә булса эштә мәкер, астыртынлык.- Егетләр хәйләсеннән сак булыгыз. Э. Әгъзәмов. 2. Берәр максатка ирешү өчен уйлап чыгарылган ялган сылтау, сәбәп, әмәл.- Бу дөньяда хәйләсез генә яшәп булмый икән? Э. Әгъзәмов.

2. Нәсәдә дә булса осталык, тапкырлык, зирәклек, уйлап табучанлык.- Ул үзен бик акыллы, хәйләгә оста разведчик итеп таныта. В. Казыйханов.

3. Катлаулы, хикмәтле, аерым осталык, күнекмә таләп итә торган нәрсә турында.- Ул бу машинаның хәйләсен белеп алган.

Үз – үзеңә бәя кую.

2нче бирем.

- Алдау, ялган белән бәйләнешле нинди мәкальләр беләсез?

- Алдакның аягы кыска. Алдашсаң –абруең китәр, тиргәшсәң – кадерең китәр. Ялган белән дөнья гизәрсең, кире кайта алмассың. Ялган оят китерер, дөреслек куәт китерер. Ялган сөйләмәсәң үкенечтә булмассың. Ялган сөйләсәң – тотылырсың, дөрес сөйләсәң – котылырсың. Ялган сүзне дөресләү таш ватудан авыррак. Ялган сүзенең гомере кыска.

Үз – үзенә бәя кую.

3 нче бирем.

- Хәзер дәреснең башында укылган хикәягә кайтыйк. Азатны ялганлауга нәрсә этәргән?

- Ялкаулык.

- Ул нәрсәдән килә?

- Эш яратмаудан, иренгәнлектән.

- Бу сыйфатлар аңа тумыштан бирелгәнме?

- Юк, әлбәттә.

- Ә нилектән?

- Ихтыяр көче җитмәүдән.

- Аны кайдан алып була?

- Аны бәләкәйдән үк үзеңдә тәрбияләргә кирәк.

Үз – үзеңә бәя кую.

4 нче бирем.

- Алдауның, ялганның кешеләр дөньясына ясаган зыяны турында мисаллар китерегез. (Коллективта, дуслар, туганнар арасында, гаиләдә, мәктәптә, Җитәкче вазифалар башкарганда, хәрби хезмәттә һ. б.)

Үз – үзеңә бәя кую.

5 нче бирем.

- Алдау, ялганлау кебек сыйфатларны үзеңдә булдырмау өчен нәрсәләр эшләргә кирәк? Дәфтәрегезгә план рәвешендә языгыз.

Көтелгән план үрнәге:

1. Һәр кушылган, тапшырылган эшне үз вакытында җиренә җиткереп үти барырга.
2. Бүгенге эшне иртәгә калдырмаска.
3. Көндәлек эшкә анализ ясап барырга.
4. Үзеңдәге бер генә кимчелеккә дә күз йомып калмаска.
5. Кешеләрдәге уңай сыйфатларны кабул итәргә өйрәнергә һ. б.

Үз – үзеңә бәя кую.

IV. Рефлексия.

Бүгенге дәрестә нәрсә турында сөйләштек? Аннан сез нинди нәтиҗәләр ясадыгыз? Дәрес кайсы ягы белән файдалы булды?

Дәрес өчен үз – үзеңә бәя кую.

V. Өйгә эш бирү.

1. Гаиләдә тикшерегез: алдауның һәм ялганның гаиләгә зарары. Нинди мисалларда моны күрсәтә аласыз?

2. Иҗади эш.